ГЛАВА АЗАЛАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 ел ,15 ноябрь. № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Азалак авылы гражданнарының 2023 елда узарара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-РТЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2022 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Азалак авылы, Совет урамы, 22А йорты адресы буенча урнашкан Азалак авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның узарара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне түбәндәгечә расларга: “I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт һәм контракт буенча узучы хезмәткәрләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 2023 елда 300 сум узара салым җыярга һәм күләмендә кертергә, шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тоторга Сез ризамы:

- Азалак авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- Азалак авылында (Сабантуй, юбилейлар, 9 Май, өлкәннәр көне, инвалидлар көне) массакүләм чаралар үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Азалак авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Азалак авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Азалак авылы зираты өчен вата торган чүкеч сатып алу;
- бензин чапкычлары, ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары һәм Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Беларусь МТЗ-82.1 тракторына , ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары өчен запас частьләр сатып алу;
- Азалак авылында Елга урамы буенча юлларны ремонтлау ( махсус техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, таш ташу һәм вак таш җәю, юл өслеген тигезләү);
- Азалак авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар җыелу урыннарын чистарту (махсус техника арендалау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

“ӘЙЕ” “ЮК?”

3. Әлеге карарны 7 көн эчендә Азалак авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмәти стентларда урнаштырырга, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, https://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

РТ Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Габдулгазизов